МИНИСТЕРСТВО СПОРТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

25.02.2019 Казан ш. № 52

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы комиссиясен төзү турында

2004 елның 27 июлендә кул куелган 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте турында», 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» федераль законнары, 2010 елның 1 июленнән Россия Федерациясе Президентының 821 нче номерлы «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссияләр турында» боерыгы, 2003 елның 16 гыйнвареннән 3-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августында кабул ителгән УП-569 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссияләр турында» боерыгы буенча **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы комиссиясен төзергә (алга таба – Комиссия).

2. Комиссия турында теркәлә торган Нигезләмәне расларга.

3. Кадрлар мәсъәләләре һәм гражданлык хезмәте буенча секторга (Л.Н.Тайшибаева) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәүгә юлларга.

4. Кадрлар мәсъәләләре һәм гражданлык хезмәте буенча секторга (Л.Н.Тайшибаева) дәүләти гражданлык хезмәткәрләрен әлеге боерыкның 2 пунктында расланган Нигезләмә белән таныштырырга һәм аны Министрлык сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз артымда калдырам.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
2019 елның 25 февралендә кул
куелган 52 номерлы
Боерыгы белән
расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТИ ГРАЖДАНЛЫК ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ТӘРТИБЕНӘ ТАЛӘПЛӘРНЕ САКЛАУ ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘР КАРШЫЛЫГЫН КӨЙЛӘҮ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Яшьләр Спорт министрлыгында (алга таба – Министрлык) 2004 елның 27 июлендә кул куелган 79-ФЗ номерлы « Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте турында» , 2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы « Коррупциягә каршы тору турында» федераль законнары, 2010 елның 1 июленнән Россия Федерациясе Президентының 821 нче номерлы « Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссияләр турында» боерыгы, 2003 елның 16 гыйнвареннән 3-ЗРТ номерлы « Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августыннан УП-569 номерлы « Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссияләр турында» боерыгы һәм әлеге Нигезләмә буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) формалаштыру һәм аның эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

2. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эшли.

3. Комиссиянең төп бурычы булып:

а) Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба –

дәүләт хезмәткәрләре) Министрлыкта чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки көйләү турында таләпләрне саклауны тәэмин итүдә, шулай ук 2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы « Коррупциягә каршы тору турында» федераль законы, башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларын үтәүне тәэмин итүдә (алга таба - Хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турында таләпләр;

б) Министрлыкта коррупцияне кисәтү буенча чараларны тормышка ашыруда ярдәм күрсәтүгә тора.

4. Комиссия Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасында (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфасы) эшли торган дәүләт хезмәткәрләренә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели һәм азат итә торган дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасында эшли торган дәүләт хезмәткәрләреннән кала) карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турында таләпләрне саклау белән бәйле мәсьәләләрне карый.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели һәм азат итә торган дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасында эшли торган дәүләт хезмәткәрләренә карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турында таләпләрне саклау белән бәйле мәсьәләләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турында таләпләрне саклау буенча Комиссия карый.

6. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турында хәбәрләрне, аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

7. Комиссиянең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Комиссия рәисе, аның Татарстан Республикасы спорт министры (алга таба – министр) Министрлыкта дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасында (алга таба – Дәүләт хезмәте вазыйфасы) эшли торган Комиссия әгъзалары арасыннан билгеләгән урынбасары, сәркатип һәм Комиссия әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары да карар кабул иткәндә тигез хокукка ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. 1. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

министр урынбасары (Комиссия рәисе), Министрлыкның кадрлар эшләре һәм гражданлык хезмәте буенча секторы мөдире, Министрлыкның кадрлар эшләре һәм гражданлык хезмәте буенча секторының коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы вазыйфаи заты (Комиссия сәркатибе), Министрлыкның юридик һәм мобилизацион эш секторы мөдире, Министрлыкның башка бүлекчәләренең министр билгеләгән хезмәткәрләре;

Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе вәкиле;

эшчәнлекләре дәүләт хезмәте белән бәйле булган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре).

8. Министр:

а) 2005 елның 14 октябрендә кул куелган 103 ЗРТ номерлы « Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 22.1 маддәсе буенча Министрлык каршында оештырылган иҗтимагый совет вәкилен;

б) Министрлыкта төзелгән ветераннар иҗтимагый оешмасы вәкилен;

в) Министрлыкта билгеләнгән тәртиптә эшли торган профсоюз оешмасы вәкилен Комиссия составына кертү турында карар кабул итә ала.

9. Әлеге Нигезләмәнең 7 һәм 8 пунктларында күрсәтелгән затлар Комиссия составына билгеләнгән тәртиптә министр соравы буенча тиешле органнар һәм оешмалар белән килешенеп кертелә. Килештерү сорау алынганнан соң 10 көн вакыт эчендә тормышка ашырыла.

10. Комиссиянең Министрлыкта дәүләти гражданлык хезмәтен башкармый торган әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми санының $1/4$ өлешеннән дә азрак булырга тиеш түгел.

11. Комиссия составы Комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясый ала торган мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгуын юкка чыгарырлык итеп

формалаштырыла.

12. Комиссия утырышларында киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашалар:

а) Комиссия хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турында таләпләрне саклау белән бәйле мәсьәләләр карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе билгеләгән Министрлыкта Комиссия аңа карата әлеге мәсьәләне карый торган вазифада эшли торган дәүләт хезмәткәре белән охшаш вазифа башкара торган ике дәүләт хезмәткәре;

б) Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасы башкара торган башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьләләре һәм Комиссия карый торган мәсьәләләр буенча аңлатма бирә ала торган белгечләр; башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органарының вазыйфаи затлары; кызыксынган оешмалар вәкилләре; Комиссия аңа карата хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турында таләпләрне саклау белән бәйле мәсьәләне карый торган дәүләт хезмәткәренең вәкиле – Комиссия утырышына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча Комиссия рәисенең һәр конкрет очракта аерым кабул иткән карары буенча Комиссия аңа карата әлеге мәсьәләне карый торган дәүләт хезмәткәренең үтенеч язуы (ходатайствосы) нигезендә.

13. Комиссия утырышы, анда Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә 2/3 катнашса, тулы хокуклы дип санала. Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын башкара торган Комиссия әгъзалары гына катнашкан утырышлар үткәрү мөмкин түгел.

14. Комиссия әгъзасының Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул, утырыш башланганчы, бу хакта хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта комиссия әгъзасы әлеге мәсьәләне карауда катнашмый.

15. Комиссия утырышын уздыру өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

а) министрның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт хезмәткәрләре тапшыра торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре һәм дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата

таләпләрне саклавын тикшерү нәтиҗәләре буенча:

Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабреннән УП-702 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәдә каралган белешмәләрне, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне дәүләт хезмәткәренең дөрес булмаган яисә тулы булмаган рәвештә бирүе турында;

дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәмәве турында раслый торган тикшерү материалларын бирүен раслый торган күрсәтмәсе;

б) Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча секторына Министрлыкның норматив-хокукый актларында билгеләгән тәртиптә кергән:

Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгәндә Татарстан Республикасы Дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларының министр боерыгы белән расланган исемлегенә (алга таба – исемлек) кертелгән гражданның хезмәт килешүе шартларында коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләп торуга яки, әлеге оешма белән дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, эштән азат ителгән көннән соң ике елга кадәр вакыт эчендә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкарырга рөхсәт бирү турында мөрәҗәгате;

дәүләт хезмәткәре хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны объектив сәбәпләр буенча тапшырырга мөмкин булмавы турында

гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең счетлары (кертемнәре) саклана һәм (яки) чит ил финанс инструментлары булган территориядә урнашкан чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә алар белән эш итәргә арест, тыю салынганга яисә үзенең ихтыярына яки аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартларга бәйле рәвештә, 2013 елның 7 маеннан 79-ФЗ номерлы « Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетларын (кертемнәрен) ачу һәм аларга ия булуны, акчаларын һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» Федераль законы таләбен үтәү мөмкинлеге булмау турында гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында белдерүе;

в) министрның яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәүне тәэмин итүгә яки Министрлыкта коррупцияне кисәтү буенча чараларны тормышка ашыруга кагыла торган күрсәтмәсе;

г) министрның 2012 елның 3 декабрендә кабул итлегән « Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ номерлы федераль законның 3 маддәсе 1 өлешендә каралган дәүләт хезмәткәренең төгәл яки тулы булмаган мәгълүмат тапшыруы турында раслый торган тикшерү материалларын тапшыруы;

д) әгәр Министрлыкта вазыйфа биләгән вакытта әлеге оешма белән дәүләт идарәсенең аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, Комиссия аңа элегрәк күрсәтелгән оешма белән хезмәт һәм граждан-хокукый мөнәсәбәтләргә керүдән баш тартса яисә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада мондый гражданга вазыйфа биләү өчен ризалык бирү яисә коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында

аларга эш башкару мәсьәләсе комиссия тарафыннан каралмаган булса, 2008 елның 25 декабрендә кул куелган « Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 маддәсе 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 маддәсе нигезендә Министрлыктагы дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче граждан белән эшләр (хезмәт күрсәтүләр) башкаруга хезмәт яисә гражданлык-хокукый килешүен төзү турында коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмадан кергән хәбәр.

16. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән граждан тарафыннан Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре секторына коррупциячел һәм башка хокук бозуларны кисәтү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшырыла. Мөрәҗәгатьтә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, аның туган көне, яшәү урынының адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көнгә кадәр соңгы ике ел эчендә биләгән вазыйфалары, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешманың атамасы, урнашу урыны, аның эшчәнлеге характеры, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмага карата дәүләт идарәсе буенча функцияләре, килешү төре (хезмәт яисә гражданлык-хокукый), аның күздә тотылган гамәлдә булу срогы, эш (хезмәт күрсәтүләр) шартнамәсе буенча башкарган (күрсәткән) өчен түләү суммасы күрсәтелә. Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча секторының коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан мөрәҗәгать карау гамәлгә ашырыла, 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән « Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 маддәсе таләпләрен исәпкә алып, аның нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгатьнең асылы буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.

16.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне дәүләт хезмәтеннән чыгуны планлаштыра торган дәүләт хезмәткәре бирергә мөмкин һәм, мөрәҗәгать әлеге Нигезләмә нигезендә комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

16.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « д» подпунктында күрсәтелгән

хәбәрнамә Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча секторының коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан карала, ул Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданның 2008 елның 25 декабреннән 273-ФЗ номерлы « Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законының 12 маддәсе таләпләрен үтәве турында дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

16.3. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамә министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре секторы тарафыннан карала, ул хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра.

16.4. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән Бәяләмәне яисә әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктында һәм әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « д» подпунктында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне әзерләгәндә, Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча секторның вазыйфаи затлары мөрәҗәгатьне яисә хәбәрнамәне тапшырган дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә яки аңардан язмача аңлатмалар алырга, ә министр яисә аның моңа махсус вәкаләте булган урынбасары билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга запрослар җибәрә ала. Мөрәҗәгать яки хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки хәбәрнамә кергән көннән җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Запрослар җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки хәбәр кергән көннән алып 45 көн эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык түгел.

16.5 16, 16.2, 16.3 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләр түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының икенче һәм бишенче абзацларында һәм « д» подпунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә белдерүләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнары һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 15 пункты « б» подпунктының икенче һәм бишенче абзацларында һәм « д» подпунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм мөрәҗәгатьләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 23, 24.2, 25.2 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.

17. Комиссия Рәисе Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат аңа Закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә кергәндә:

а) 10 көн вакыт эчендә Комиссия утырышы датасын билгели. Җитмәсә комиссия утырышы датасы, әлеге Нигезләмәнең 17.1 һәм 17.2 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән соң 20 көннән дә соңга калмыйча билгеләнә алмый;

б) Комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәү турындагы мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең, аның вәкиленең һәм комиссия утырышында катнашучы башка затларның Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре секторына яисә коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка кергән мәгълүмат, аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) әлеге Нигезләмәнең 12 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән затларны комиссия утырышына чакыру турындагы үтенечнамәләрне карый, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карап тикшерү турында Карар кабул итә.

17.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән вакыт чыкканнан соң бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

17.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « д» подпунктында күрсәтелгән

мөрәҗәгать, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.

18. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, аңа карата хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәү турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре катнашында үткәрелә. Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында дәүләт хезмәткәре яисә граждан әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпункты нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә күрсәтә.

18.1. а) Әгәр әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктында каралган мөрәҗәгатьтә, гариза яки хәбәрнамәдә дәүләт хезмәткәре яисә гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтелмәгән булса;

б) әгәр Комиссия утырышында шәхсән катнашырга нияте булып, аны уздыру вакыты һәм урыны турында аңа тиешле рәвештә хәбәр ителгән булса да, дәүләт хезмәткәре яисә граждан Комиссия утырышына килмәсә

Комиссия утырышлары дәүләт хезмәткәре яисә граждан булмау очрагында үткәрелергә мөмкин.

19. Комиссия утырышында Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән хезмәткәр яки гражданның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңланыла, әлеге утырышка чыгарылган мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

20. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашучы затлар Комиссия эше барышында үзләренә билгеле булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

21. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « а» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кыла торган гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30

декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган Нигезләмә буенча дәүләт хезмәткәрләре тапшырган белешмәләрнең дөрес һәм тулы булуын билгеләргә;

б) әлеге пунктның « а» подпунктында аталган Нигезләмә нигезендә дәүләт хезмәткәрләре тапшырган мәгълүматларнең дөрес түгел һәм (яисә) тулы булмаган икәнлеген билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

22. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « а» подпунктының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәгән дип билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәре хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәмәде дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне бозуга юл куймауны күрсәтә яисә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

23. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яисә, әлеге оешма белән дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән очракта, гражданлык-хокукый килешү шартларында эшне башкаруга ризалык бирергә;

б) гражданга коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада яисә гражданлык-хокукый килешү шартларында, әлеге оешма белән дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, эшне башкарудан баш тартырга һәм үз баш тартуларына аңлатма бирергә.

24. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның

берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең хатыны (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны бирмәүнең сәбәбен объектив һәм нигезле булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең хатыны (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирмәүнең сәбәбен нигезле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә әлеге мәгълүматны тәкъдим итү буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәрләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирмәүнең сәбәбе объектив түгел дип һәм күрсәтелгән мәгълүматларны тапшырудан качу ысулы булып тора дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

24.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) « Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетларын (кертемнәрне) ачуны һәм булдыруны, акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) файдалануны тыю турында» федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган хәлләрне объектив һәм нигезле дип танырга;

б) «Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетларын (кертемнәрне) ачу һәм булдыруны, акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) файдалануны тыю турында” федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулый торган хәлләрне объектив һәм нигезле түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

24.2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы юк дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) министрга мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу яки аның барлыкка килүен булдырмау буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) дәүләт хезмәткәренең мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәвен танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга тәкъдим итә.

25. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «в» подпунктында каралган мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия тиешле карар кабул итә.

25.1. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «г» подпунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Дәүләт вазыйфаларын били торган затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» федераль законның 3 маддәсе 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәрләре тапшырган мәгълүматларны дөрес һәм тулы дип танырга;

б) «Дәүләт вазыйфаларын били торган затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» федераль законның 3 маддәсе 1 өлеше нигезендә дәүләт хезмәткәрләре тапшырган мәгълүматларны дөрес һәм тулы булмавын танырга. Бу очракта Комиссия министрга дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә һәм (яки) чыгымнарны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки) аларның компетенциясе буенча башка дәүләт органнарына җибәрергә тәкъдим итә.

25.2..2. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «д» подпунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын били торган гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданны коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа биләүгә яисә, әгәр бу оешма белән дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, гражданлык-хокукый килешү шартларында коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада эш башкаруга ризалык бирергә;

б) гражданның хезмәт килешүе шартларында коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада вазыйфаларны биләве һәм (яки) коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешмада эшләр башкаруы (хезмәтләр күрсәтүе) 2008 елның 25 декабрендә кул куелган 273-ФЗ номерлы « Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12 маддәсе таләпләрен боза дип билгеләргә. Бу очракта Комиссия министрга әлеге хәлләр турында прокуратура органнары һәм моны хәбәр иткән оешмага хәбәр итәргә тәкъдим итә.

26. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « а» - « д» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, моңа нигез булганда, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 21-24.2, 25.1-25.2 пунктлары белән каралган башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

27. Комиссия карарларын үтәү өчен Министрлыкның билгеләнгән тәртиптә министр каравына тапшырыла торган норматив хокукый актлары проектлары, министр карарлары һәм күрсәтмәләре әзерләнергә мөмкин.

28. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары (әгәр Комиссия башка карар кабул итми икән) яшерен тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

29. Комиссия карарлары утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары кул куйган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Комиссия карарлары, әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карарлардан тыш, министр өчен тәкъдим итү

характерында була. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри характерга ия.

30. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) комиссия утырышы уздырылган дата, комиссия әгъзаларының һәм утырышта катнашучы башка затларның фамилияләре, исеме, атасының исеме;

б) комиссия утырышында хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәренең һәрберсенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын күрсәтеп формулировкасы;

в) дәүләт хезмәткәренә карата дәгъвалар, аларга нигезләнә торган материаллар;

г) дәүләт хезмәткәре һәм башка затларның дәгъваларның асылы буенча аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилияләре, исеме, атасының исеме һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат чыганагы, министрлыкка мәгълүмат керү датасы;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне нигезләү.

31. Комиссия карары белән риза булмаган Комиссия члены үз фикерен язма рәвештә белдерергә хокуклы, ул комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә һәм дәүләт хезмәткәре аның белән таныштырылырга тиеш.

32. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәләре утырыш көненнән соң 7 көн эчендә министрга, тулысынча яки аннан күчермә рәвешендә – дәүләт хезмәткәренә, шулай ук комиссия карары буенча – башка кызыксынган затларга җибәрелә.

33. Министр Комиссия утырышы беркетмәсен карарга бурычлы һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылык чараларын куллану турында, шулай ук коррупциягә каршы көрәшне оештыруның башка мәсьәләләре буенча карар кабул иткәндә үз компетенциясе

чикләрендә булган тәкъдимнәрне исәпкә алырга хокуклы. Министр Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында Комиссиягә Комиссия утырышы беркетмәләре кергән көннән соң бер ай вакыт эчендә язмача хәбәр итә. Министр карары комиссиянең якындагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышудан башка исәпкә алына.

34. Дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) Комиссия тарафыннан дисциплинар адым билгеләре ачыкланганда, бу хакта мәгълүмат дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне хәл итү өчен министрга житкерелә.

35. Комиссия тарафыннан дәүләт грждданлык хезмәткәренең административ хокук бозу билгеләре яисә җинаять составы булган гамәлләр (гамәл кылмау очрагы) факты (гамәл кылмау очрагы) билгеләнгән очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәл кылу (гамәл кылмау) турында мәгълүматны һәм мондый фактны раслый торган документларны 3 көн вакыт эчендә, ә зарури булганда – кичекмәстән тапшырырга тиеш.

36. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан өземтә аңа карата хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәү турындагы мәсьәлә каралган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә беркетелә,.

3.1. Комиссия секретаре имзасы һәм министрлык мөһере белән расланган Комиссия карарыннан өземтә әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы « б» подпунктының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын били торган гражданга тиешле Комиссия утырышын уздыру көненнән соң килүче көндә имзасын куйдырып тапшырыла яисә мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча тапшырылуы турында хәбәрнамәле заказ хаты белән җибәрелә.

37. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирү, комиссия утырышында

фикер алышу өчен тәкъдим ителә торган материаллар белән таныштыру, кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре секторының коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.